**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3753**
**10.05.2023**

Башкарма комитетның аерым
карарлары үз көчен югалтуны
тану турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2020 елның 3 июнендә «Челнинские известия» газетасының 40 нчы санында бастырып чыгарылган һәм 2020 елның 5 июнендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 29 маендагы 2569 номерлы карары;

2) 2021 елның 10 февралендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 5 февралендәге 773 номерлы карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов